## Туган телем – татар теле

# Әкиятләр яратам

(7 нче дәрес)

# Елмаеп алыйк әле!

**Алдавыч әкият**

Борын-борын заманда торганнар, ди,
Агай-энеле ике туган.
Берсенең исеме **Сөйлә** булган, ди,
Икенчесе **Сөйләмә** булган.
Беркөнне **Сөйлә** базарга киткән.
Киткән бу, киткән...
Тукта, кайсысы өйдә калган?

- **Сөйләмә**.
- Алай булгач сөйләмим.



*алдавыч – *здесь:* обманный

# Калач

## (Әкият)

Карт белән карчык булган, ди. Беркөнне аларның ашарларына бетә. Карчык соңгы онны ала да тиз генә бер калач ясый. Калачны пешереп, тәрәзә төбенә куюга, Калач җиргә сикереп төшә һәм тәгәрәп китеп тә бара.

Бара торгач, аңа Бүре очрый.

- Кая барасың, Калач? – ди Бүре. – Минем карыным ач, хәзер сине ашыйм, - ди.
- Син мине ашама, - ди Калач, - мин сиңа җыр җырлармын.
- Я, җырла, - ди Бүре. Калач җырларга тотына.
- Әбиемнән дә качтым мин,

Бабамнан да качтым мин,
Синнән качам да качам, -

дип, Бүрене узып та китә.

*Әкиятне дәвам итеп сөйлә!*





**Дәрес тәмам, дуслар!**

**Сау булыгыз!**